ГЛАВА АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.28, с. Албай, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422176

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

№ 4 — от 30.10.2019г.

Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Албай авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча узган гражданнар җыенында катнашучы затларны теркәү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Албай авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында" гы 2019 елның 16 октябрендәге 2-46 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәнең 3.1 пункты нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Албай авылы китапханэ мөдире Мишурина Любовь Михайловнаны Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегенең Албай торак пунктында 2019 елның 13 ноябрендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенында катнашучы сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен җаваплы итеп билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында катнашучы затларны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә теркәүне тәэмин итәргә.

3 Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Албай авыл җирлеге башлыгы: И.П. Крешков

СОВЕТ АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ГЛАВА АЛБАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.28, с. Албай,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422176

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛБАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, Албай авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422176

тел.(факс): (85563) 3-05-08; e-mail: Alb.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление
№ 5

Карар
30 октябрь 2019ел.

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегенең Югары Эрнэш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Албай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге" Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Югары Эрнэш авылы , “Руслан” кибете бинасы янында 2019 елның 11 ноябрендә сәгать 9.00 дә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегенең Югары Эрнэш авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлегенең Югары Эрнэш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Албай торак пунктында зиратка баручы юлны, Югары Эрнэш авылында Максим урамы буенча баручы юлны вакташ җәеп ремонтлау;

- Албай торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Албай авыл җирлеге башкарма комитетына Югары Эрнэш авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Албай авыл җирлеге башлыгы: И.П. Крешков